ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«ГОРОД АГРЫЗ» АГРЫЗСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
«ӘГЕРҖЕ ШӘҺӘРЕ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕНЕН
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**КАРАР** **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

16.12.2019 Әгерҗе ш. № 31

2020 елга Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Әгерҗе шәһәре» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты тарафыннан үтәлүе бәяләнгән юридик затлар һәм индивидуаль эшкуарлар тарафыннан мәҗбүри таләпләрне бозуны кисәтүгә юнәлтелгән профилактик чаралар программасы турында

«Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль законның 8.2 статьясы, «Дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның хокукларын яклау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2018 елның 26 декабрендәге 1680 номерлы карары, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Әгерҗе шәһәре» муниципаль берәмлеге башкарма комитеты тарафыннан билгеләнгән мәҗбүри таләпләрне бозуларны профилактикалау чараларын оештыруның һәм гамәлгә ашыруның гомуми таләпләрен раслау хакында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2018 елның 26 декабрендәге 1680 номерлы карары нигезендә **КАРАР ИТТЕ:**

1. 2020 елга Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының “Әгерҗе шәһәре” муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты тарафыннан үтәлүе бәяләнгән юридик затлар һәм индивидуаль эшкуарларның мәҗбүри таләпләрне бозуны кисәтүгә юнәлдерелгән профилактик чаралар программасын расларга (1 нче кушымта).

2. 2020 елга законнарның һәм башка норматив хокукый актларның мәҗбүри таләпләрен бозуны кисәтүгә юнәлдерелгән профилактик чараларның План-графигын расларга (2 нче кушымта).

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районы сайтында http://agryz.tatarstan.ru,

Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга http://pravo.tatarstan.ru

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының “Әгерҗе шәһәре” муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Р.Р. Вәлиевка йөкләргә.

Җитәкче Ә.М.Рәхмәтулин